БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

"16" 05 2022 ел № 189

«Балтач район башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 8 августындагы 708 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына (2021 елның 6 февралендәге 74 номерлы үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 81 статьясы нигезендә Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2012 елның 8 августындагы 708 номерлы карары (2021 елның 6 февралендәге 74 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Балтач район башкарма комитетының резерв фонды акчаларын тоту тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Резерв фонды акчалары түбәндәгеләрне финанслауга тотыла:

- коткару, авария-торгызу эшләре һәм районда стихияле бәла-каза һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү белән бәйле башка чаралар уздыру;

- торак урыннары һәм (яки) хуҗалык корылмалары табигый бәла-казалар, янгын һәм башка гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән гражданнарга (милекчеләргә, торак биналарны наемга алучыларга) табигый бәла-казалардан һәм янгыннан зыян күргәндә бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм түләүләре;

- аларга бәйле булмаган хәлләр аркасында авыр матди хәлдә калган һәм ашыгыч медицина ярдәменә мохтаҗ булган гражданнарга бер тапкыр бирелә торган матди ярдәм;

- социаль әһәмиятле проектларны гамәлгә ашыру өчен иҗтимагый оешмаларга һәм берләшмәләргә ярдәм итү;

- социаль әһәмиятле объектларда кичектергесез ремонт һәм торгызу эшләре;

- җирле әһәмиятле проблемалар буенча очрашулар, күргәзмәләр һәм семинарлар уздыру;

- Татарстан Республикасы Балтач район Советы һәм Балтач район башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитет) карары буенча үткәрелә торган муниципаль программаларда каралмаган социаль әһәмиятле өлкәләрдәге башка чараларны финанслау.»;

1.2. 4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Резерв фонды акчалары түләүсез һәм кире кайтарылмый торган нигездә бирелә.

Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән көтелмәгән чыгымнарны һәм җирле әһәмиятле чараларны финанслауга башкарма комитетның резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү физик яисә юридик затның башкарма комитетка мөрәҗәгать итүе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Физик һәм юридик затлар башкарма комитет җитәкчесенә башкарма комитетның резерв фондыннан акча бүлеп бирү турында мөрәҗәгать белән бергә билгеләнгән максатларга чыгымнарның кирәклеген, кичектергесез һәм көтелмәгән булуын раслаучы документлар (органнарның китерелгән зыян турында яисә смета-финанс хисапларын, калькуляцияне, чыгымнарның накладнойларын, счет-фактураны һәм проект-смета документациясен кертеп, таләп ителә торган күләмне дәлилли торган белешмәләрне) тапшыра;

1.3. 4.5 пунктта:

«күрсәтмә» сүзеннән соң «җитәкче» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«башкарма комитет җитәкчесенең күрсәтмә проектын әзерләү максатларында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына, әлеге Нигезләмәнең 4.3 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән документларны кушып, резерв фондыннан акчалар бүлеп бирү турында мөрәҗәгать күчермәсе җибәрелә.»;

1.4. 5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Резерв фонды акчалары бүлеп бирелә торган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм оешмалар, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә акчалардан максатчан файдаланмаган өчен җавап тоталар һәм тиешле чаралар уздырганнан соң бер ай эчендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына, раслаучы документларны беркетеп, бүлеп бирелгән акчаларның максатчан тотылуы турында хисап тапшыралар.»;

1.5. 5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Башкарма комитетның резерв фондының бюджет ассигнованиеләреннән файдалану турында хисабы тиешле бюджет үтәлеше хакындагы еллык хисапка кушымта итеп бирелә.»;

1.6. 5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Бирелгән акчаларны үзләштермәгән, файдаланучы тарафыннан бирелгән акчалардан максатчан файдалануны бозган, дөрес булмаган белешмәләр булган документларны тапшырган очракта, акчалар Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиеш.

Акча бирүне туктату һәм (яисә) акчаларны кире кайтару турында карарны башкарма комитет җитәкчесе кабул итә.».

2. Юридик затлар өчен Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башкарма комитетының резерв фондыннан бирелгән акчалардан максатчан файдалану турында хисап формасын расларга (1 нче кушымта).

3. 2023 елның 1 гыйнварына кадәр 2.2 пунктының гамәлдә булуын резерв фонды күләменә таләпләр өлешендә туктатып торырга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә https://baltasi.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Балтач

муниципаль районының рәсми сайтында һәм https://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе                                                                 А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2022 елның «16» 05 2022
189 номерлы карарына
1 нче кушымта

Балтач район башкарма комитетының
резерв фондыннан бирелгән акчалардан максатчан файдалану турында
__________ елгы
хисабы

Акча алучы исеме

_______________________________________________

Салым түләүченең идентификация номеры (ИНН)

_______________________________________________

Үлчәү бердәмлеге: сум.

_______________________________________________

| Чыгымнарның юнәлешләре | Бирелгән акча (сум) | Фактта финансланган (сум) | Файдаланылмаган акчаларның калган өлеше (сум) | искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| | | | | |

Җитәкчесе ________ ______________ баш хисапчы ________ _____________
имза имзаның тулы формасы имза имзаның тулы формасы

"_"_________ 20__ ел
М.У. *(булган очракта)*